**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«01» июль 2016 ел Күзкәй авылы № 29

Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең
административ регламентларны раслау турында карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1.Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 28 апрелендәге 3 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Документларның һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. Васыятьнамәләр таныклыгы һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Җир кишәрлегенә белешмә, йорт хуҗаларына белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урынынннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Гәрәев